МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.03.2024 Казан ш. № 143-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына үзгәрешләре кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүгә бәйле боерам:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелгән үзгәрешләрне расларга.
2. Әлеге боерыкның башкарылуын контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары А.И.Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
13.03.2024 № 143-пр
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының аерым боерыкларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген сатулашулар аша бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 04.08.2022 № 489-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлеген сатулашулар аша бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентында:

2.8.2 пунктның 14 подпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14) җир кишәрлеге комплекслы үсеше турында шартнамә төзелгән яисә Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Россия Федерациясе яки Россия Федерациясе субъекты билгеләгән юридик зат тарафыннан гамәлгә ашырылу турында карар кабул ителгән төзелешле территория чикләрендә урнашкан»;

3.6.2.2 пунктның унөченче абзацын көчен югалткан дип танырга;

2. Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 04.08.2022 № 488-пр боерыгы белән расланган Дәүләт милкендә булган җир кишәрлекләрен гражданнарга хосусый торак төзелеше, торак пункты чикләрендә шәхси ярдәмчел хуҗалык алып бару, үз ихтыяҗларына бакчачылык өчен, гражданнарга һәм крестьян (фермер) хуҗалыкларына крестьян (фермер) эшчәнлеге алып бару өчен бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү административ регламентына кертелгән үзгәрешләр (Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 17.04.2023 № 246-пр боерыгы белән кертелгән үзгәрешләр белән):

Регламентка 3 нче кушымтаның 8 подпунктында «төзелгән территория үсеше» сүзләрен «территориянең космплекслы үсеше» сүзләре белән алыштырырга.